**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

КАРАР ______ ПОСТАНОВЛЕНИЕ

ПГ-10 06.03.2025 № ____

Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 24, 28 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законы, район Уставы, Актаныш районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл җирлекләренең Генераль планнарын эшләү турында» 2021 елның 23 апрелендәге ПР-73 номерлы карары нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча халык алдында ачык тыңлаулар уздырырга.
2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмати порталында, Уразай авыл җирлегенең мәгълүмат стендында урнаштырырга.
3. Ачык тыңлаулар турында мәгълүматны “Актаныш таңнары" газетасында бастырып чыгарырга.
4. Ачык тыңлауларны үткәрү срогын 1 көн дип билгеләргә.

- ачык тыңлаулар үткәрү вакыты-2025 елның 18 марты.:
- 10.00 сәгатьтә, үткәрелү урыны: Уразай авыл мәдәният йорты, Уразай авылы, Үзәк ур., 4нче йорт;
- 12.00 сәгатьтә, үткәрелү урыны: Илчебай мәдәният йорты, Илчебай авылы, Үзәк ур., 19 нчы йорт;
- 14.00 сәгатьтә, үткәрелү урыны: "Куян авылы мәдәният йорты" МБУ, Куян авылы, Үзәк ур., 57 нче йорт);
- 16.00 сәгатьтә, үткәрелү урыны: Шәрип авыл мәдәният йорты, Шәрип авылы, Үзәк ур., 4нче йорт;
- 18.00 сәгатьтә, үткәрелү урыны: Мерәс мәдәният йорты, Мерәс авылы, Үзәк ур., 35а йорты.

5. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе И.Р.Губаеваны гавами тыңлаулар үткәрү өчен җаваплы итеп билгеләргә.
6. Уразай авыл җирлегенең генераль планы проекты турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен, кушымта нигезендә расларга.
7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башлыгы Л.Р.Зарипов

Актаныш муниципаль районы
Башлыгы карарына
______ 2025 ел №___
кушымта

УРАЗАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАНЫ ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ФИКЕР АЛЫШУДА ГРАЖДАННАРНЫҢ КАТНАШУ ТӘРТИБЕ

Әлеге тәртип Уразай авыл җирлегенең генераль планы проекты (алга таба- Генераль план) буенча фикер алышуда халыкның катнашуын тәэмин итү максатларында эшләнгән һәм авыл җирлеге гражданнарының Генераль план проекты буенча фикер алышуда катнашу, шулай ук Генераль план проекты буенча халык фикерен исәпкә алу тәртибен җайга сала.

1. Гражданнарның Генераль план проекты буенча фикер алышуда катнашуы халыкның Генераль план проекты буенча гавами тыңлауларда катнашуы һәм авыл җирлегендә яшәүчеләрнең Генераль план проекты буенча язма тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен Актаныш районы Башкарма комитетына җибәрү юлы белән башкарыла.

2. Җирлекнең генераль планы проектының график һәм текст материаллары экспозициясе Уразай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырылган.

3. Җирлекнең генераль планы проекты материаллары белән танышу вакыты: дүшәмбе-җомга - 9.00дән 16:00гә кадәр, (төшке аш 11.30 дан 13.00 гә кадәр).

4. Генераль план проекты территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында fgis.economy.gov.ru бастырылып чыгарылырга тиеш.

5. Җирлекнең генераль планы проекты буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул итү **түбәндәге адрес** буенча гамәлгә ашырыла: 423740, ТР, Актаныш ав., Ленин пр.17 й., Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, инфраструктур үсеш бүлеге;

6. Ачык тыңлауларны әзерләү һәм уздыру, шулай ук Генераль план проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итү һәм исәпкә алуны ачык тыңлауларны уздыру өчен җаваплы кеше гамәлгә ашыра.

7. Генераль план проекты буенча фикерләрне, тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алуны документлар белән тәэмин итүне ачык тыңлауларны уздыру секретаре гамәлгә ашыра.

8. Ачык тыңлаулар башланганчы секретарь тарафыннан ачык тыңлауларда катнашучыларны теркәү башкарыла. Теркәлү битендә ачык тыңлауларда катнашучыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны адресы күрсәтелә.

10. Ачык тыңлаулар уздырганда түбәндәге регламент билгеләнә:
- докладчыга төп доклад өчен 20 минуттан да артык бирелми;
- җирлекнең Генераль планы проектын тикшерү буенча чыгышлар өчен 3 минуттан артык түгел;

- репликалар һәм искәрмәләр өчен - 2 минуттан артык түгел.

11. Ачык тыңлаулар уздырганда секретарь тарафыннан Генплан проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсе алып барыла. Беркетмәгә гавами тыңлауларны оештыручы һәм секретаре кул куя.

12. Ачык тыңлауларны оештыручы ачык тыңлаулар уздырылганнан соң 2 көн эчендә ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли, анда мәҗбүри рәвештә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- ачык тыңлауга чыгарылган сорауның исеме;
- ачык тыңлаулар уздыру датасы, вакыты һәм урыны;
- ачык тыңлауларда катнашкан авыл җирлеге гражданнары саны;
- ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча карар.

14. Бәяләмәгә ачык тыңлауларны оештыручы имза сала һәм ачык тыңлаулар беркетмәсе белән бергә «Актаныш таңнары» газетасында, районның рәсми сайтында, Уразай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырылып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.